**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Ивашкино авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2022 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге составына керүче Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында үзара салым кертү турында

14 октябрь 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге составына керүче Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларда гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге составына керүче Ивашкино авылы, Әккәрәй авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз картлардан һәм 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш.

1. Алынган чараларны җибәрергә:

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- каты коммуналь калдыкларның вакытлыча җыелу урыннарын төзекләндерү буенча проект-смета документларын әзерләү, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм оештыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- иҗтимагый киңлекләрне төзекләндерү, Ивашкино һәм Әккәрәй торак пунктларында авыл территорияләрен үстерү буенча дәүләт программалары буенча катнашу өчен проект-смета документларын әзерләү һәм түләү чыгымнары.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлегенең рәсми сайтында

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге башлыгы Н.А. Емельянов